Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Борискино авыл җирлегенең Садиково авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2019 елның 26 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 114 номерлы Әлки муниципаль районының «Борискино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Борискино авыл җирлеге Советының «Борискино авыл җирлеге» составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 10 октябрендәге 113 номерлы карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борискино авыл җирлегенең Садиково авылында гражданнар җыенының 2019 елның 26 ноябрендәге 1 номерлы беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борискино авыл җирлеге составына керүче Садиково авылындагы гражданнар җыенын үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борискино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

-авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту, күперләрне ремонтлау, МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча түләүгә -220 сум;

-урамны су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, урам системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрләрен, су башнясын реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкару, урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлау өчен кирәкле материал сатып алу, су башнясын буяу, су анализы өчен чыгымнар, су башнясын лицензияләү белән бәйле чыгымнарны каплауга - 120 сум;

- урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре һәм урам утлары кулланылган энергиягә чыгымнарны түләүгә бәйле чыгымнарга–100 сум;

– чишмәләрне һәм күлләрне төзекләндерүгә бәйле чыгымнарга-70 сум;

- каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм утильләштерү өчен кирәкле төзелеш материалы, инвентарь һәм җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнар, килешү буенча штаттан тыш хезмәт хакына-40 сум.

- зиратларны тотуга( төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы һ. б.) бәйле чыгымнарга -50 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Борискино авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:

-авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту , күперләрне ремонтлау, МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм килешү буенча түләүгә -220 сум,

-урамны су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, урам системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, су үткәрү челтәрләрен, су башнясын реконструкцияләү буенча проект-смета эшләрен башкару, урам су белән тәэмин итү системасын ремонтлау өчен кирәкле материал сатып алу, су башнясын буяу, су анализы өчен чыгымнар, су башнясын лицензияләү белән бәйле чыгымнарны каплауга - 120 сум;

- урам утларын урнаштыруга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазларын урнаштыру буенча электромонтаж эшләре һәм урам утлары кулланылган энергиягә чыгымнарны түләүгә бәйле чыгымнарга–100 сум;

– чишмәләрне һәм күлләрне төзекләндерүгә бәйле чыгымнарга-70 сум;

- каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм утильләштерү өчен кирәкле төзелеш материалы, инвентарь һәм җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнар, килешү буенча штаттан тыш хезмәт хакына-40 сум.

- зиратларны тотуга( төзелеш материаллары сатып алу , килешү буенча хезмәт хакы һ. б.) бәйле чыгымнарга -50 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Борискино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Борискино авыл җирлеге башлыгы: Г.В. Самарина.